| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.01.2026 Казан ш. № 37-пр

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

07.11.2024 № 655-пр «Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

19.05.2025 № 274-пр «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 07.11.2024 № 655-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында».

3. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
26.01.2026 № 37-пр
боерыгы белән расланды

# Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бирүчеләр булып физик затлар, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләр, юридик санала (алга таба – гариза бирүче).

җир кишәрлекләрен милек итеп, арендага биргәндә - дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен сатулашуларсыз гына алырга хокукы булган физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$, $39^{20}$ статьясында (алга таба – РФ ҖК) каралган очраклар, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына арендага бирү искәрмә булып тора;

җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга биргәндә - дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр (бюджет, казна, автоном), казна предприятиеләре, үз вәкаләтләрен үтәүдән туктаган Россия Федерациясе президентларының тарихи мирасы үзәкләре, «Банк России»;

җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга биргәндә – РФ ҖК, федераль законнар, Татарстан Республикасы Җир кодексы һәм Татарстан Республикасының башка законнары белән билгеләнгән гражданнар һәм юридик затлар.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә ала.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” һәм “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – туры килгән тәртиптә – хезмәтләр реестры, Бердәм портал) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) сату-алу шартнамәсе проекты, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты яки җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, имзалау өчен гариза бирүчегә юллау;

2) җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар, әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән формада;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милеккә бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, арендага бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту турында карар) әлеге Регламентка 3 нче кушымта китерелгән формада.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мәгълүмат системасында реестр язуы формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә язма формада яки электрон документ формасында;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча һәм (яки) Бердәм порталдагы яки “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль

хезмәтләр порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы), “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, сатулар уздырмыйча түләүсез файдалануга бирү турында гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты гариза кергән көннән алып 20 календарь көн тәшкил итә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң 20 календарь көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 20 календарь көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Министрлыкта һәм МФЦда дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гариза бирүче күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Республика порталны, Республика порталын,

ЕИС «Имущество»ны, Министрлыкның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне Министрлык тарафыннан регистрацияләнә.

Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦдан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.2. Гариза Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Бердәм портал, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

2.7.3. Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза Министрлыкка кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.4. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, гариза бирелгән көнне министрлык хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтына, Бердәм порталга, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Министрлыкның дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлегенә (алга таба – Бүлек) мөрәҗәгать итсә, консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәте хезмәттәшлек турында тиешле килешү булган очракта, гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган (булган) урынына карамастан (физик затлар өчен, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп), яки урнашкан урынына карамастан (юридик затлар өчен) үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге, шул исәптән МФЦда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле запросны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлегенраслый торган кәгазьдә документлар бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне таныклауны да кертеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү каралган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм портал, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Бердәм портал, Республика порталы , ЕИС «Имущество»аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Бердәм портал, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Запрос формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган запросларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче Министрлыкның, МФЦның кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.11. Әлеге Регламент җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү очракларына, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга - күчемсез мөлкәт объектлары милекчеләренә арендага яисә милеккә бирү очракларына кагылмый.

2.10.12. Әлеге Регламентның пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларын үтәү кысаларында пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан яисә башка технологик һәм программа чараларыннан файдалану рөхсәт ителә.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза Россия Федерациясе Җир кодексының (алга таба - РФ ҖК) $39^{17}$ статьясындагы 1 пункты нигезләмәләренә туры килми;

2) документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән;

3) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итү формасы шушы регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.3. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә генә бирүдән баш тарту өчен түбәндәге шартларның берсе булса да нигез булып тора:

1) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары буенча җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гаризаның РФ ҖКның $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора;

3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек яки бакчачылык коммерциячел булмаган ширкәтенә бирелгән җирне бүлеп ясалган; әлеге коммерциячел булмаган ширкәтнең әгъзасы (әлеге җир кишәрлеге бакча яки яшелчә җире булса), яисә коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукы булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яки чираттан тыш сатып алу хокукына ия булган яки РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алу хокукына ия (әгәр андый җир кишәрлеге бакча кишәрлеге булса) граждан, шулай ук, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек яки бакчачалык эше алып барган территория чигендәге җир кишәрлекләренең милек иясе (җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут, гаммәви сервитут шартларында, яки РФ ҖКның $39^{36}$ статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың,

төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар, шулай ук, җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән һәм әлеге җир кишәрлегендә үзбелдекле төзелгән бинаны, корылманы, төзелеп бетмәгән объектны сүтү турында, яки үзбелдекле төзелешне сүтү яисә билгеләнгән срокларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында кабул ителгән карар һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 55[32] статьясының 11 өлеше үтәлмәгән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милек булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан булса, әлеге җир кишәрлегендә урнашкан корылмаларның (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылмаларның) җир кишәрлегендә урнашуы сервитут шартларында, гаммәви сервитут шартларында рөхсәт ителсә яки РФ ҖК 39[36] статьясына туры китереп урнаштырылган объектлар булса, яки җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән әлеге бина, корылма, алардагы бүлмәләрнең, әлеге төзелеп бетмәгән объектның хокук иясенең чыгуы чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яисә әйләнеше чикләнгән булса һәм аны бирү җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән хокукта каралмаган булса;

7) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка куелган булса, ә гариза бирүче җир кишәрлеген милеккә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану өчен яки җир кишәрлеген арендага, җир кишәрлегенең резервы турындагы карарның гамәлдәге вакытыннан озынрак срокка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә, җир кишәрлеген резервка кую максатларында бирү очрагы чыгарма булып тора;

8) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә территория чикләрендә урнашкан булса, җир кишәрлеге бирү турында шушы җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмә, төзелеп бетмәгән объект милекчесенең яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә территория чикләрендә урнашкан булса, яки җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган булса, әлеге җир кишәрлегенең федераль дәрәҗәдәге

объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булып, шул җир кишәрлеген бирү турында күрсәтелгән объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган, яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә, һәм территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса, җир кишәрлеген арендага бирү турында территорияне комплекслы үзләштерү буенча шартнамә төзелгән яки әлеге объектларны төзү бурычы куелып, территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турныда хәбәр РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 4 пункты 6 подпунктында каралган аны сату буенча аукцион үткәрелү, яки әлеге җир кишәрлеге РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 4 пункты 4 подпункты нигезендә ясалган булып, вәкаләтле орган тарафыннан РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән очракта, аренда шартнамәсенә хокукка аукцион үткәрелү турында гариза кергән булса;

13) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлегенә бирү турында РФ ҖК $39^{18}$ статьясының 1 пункты 1 подпункты нигезендә хәбәр бастырылган һәм урнаштырылган булса;

14) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегеннән файдалану максаты билешмәләре Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төренә яисә җир кишәрлегеннән файдалануның территориядән файдалану регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төрләренә туры килми. Әгәр гаризада күрсәтелгән максат өчен мондый җир кишәрлеге җир категориясенә һәм рөхсәт ителгән файдалану төренә бәйсез рәвештә файдаланылырга мөмкин булса, шулай ук линия объекты территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә урнаштырылган очракта әлеге подпунктның нигезләмәләре кулланылмый;

15) соралган җир кишәрлеге тулысынча территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, җир кишәрлеген куллануның билгеләнгән чикләүләре җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән куллану максатларына туры килми;

16) соралган җир кишәрлеге, оборона һәм иминлек ихтыяҗында куллану өчен бирелгән һәм вакытлыча күрсәтелгән максатларында файдаланылмаган җир кишәрлекләренең Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган исемлегенә кертелмәгән булса, җир кишәрлеген бирү турында РФ ҖК $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпункты нигезендә мөрәҗәгать ителгән очракта;

17) җир кишәрлеген бакчачылык, яшелчәчелек ширкәтенә бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы РФ ҖК $39^{10}$ статьясының 6 пунктында билгеләнгән чикләрдәге зурлыктан артса;

18) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яисә) территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә, федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса, мондый җир кишәрлегендә урнашкан биналарның, корылмаларның, андагы урыннарның хокук иясе, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе, мондый җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән зат гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

19) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә биналар, корылмалар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса, мондый җир кишәрлегендә урнашкан биналарның, корылмаларның, андагы урыннарның хокук иясе, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе, мондый җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән зат гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

20) җир кишәрлеген хокукларның билгеләнгән төрендә бирү рөхсәт ителми;

21) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата файлануның рөхсәт ителгән төрләре билгеләнмәгән;

22) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге җирләрнең аерым категорияләренә кертелмәгән;

23) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәттә аны бирүне алдан килештерелү турында карар кабул ителгән һәм

карарның срогы чыкмаган, әлеге җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать итсә;

24) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып тартып алынган һәм әлеге җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатлар әлеге җир тартып алынган максатларга туры килмәсә, тузган булып танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш булган күп фатирлы йортның әлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып тартып алынган җир кишәрлегендә урнашкан булуы чыгарма булып тора;

25) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль Закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

26) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне ызанлау проектында яки җир кишәрлеге барлыкка китерелгән урман кишәрлекләренең проект документациясендә җир кишәрлеге күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк зуррак булса;

27) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеше турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясындагы 4 бүлегендә каралган дәүләт милке яки муниципаль милек исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булмаган зат, яисә Федераль законның 14 статьясының 3 бүлеге нигезендә ярдәм күрсәтелми торган зат мөрәҗәгать итсә;

28) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы җирләреннән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге (алга таба – гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге), яисә гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген дә исәпләп, бирелгән җир кишәрлекләренең мәйданы крестьян (фермер) эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән җир кишәрлекләре мәйданына туры килми;

29) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге алдарак кергән җир кишәрлеген бирү турында гариза буенча дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен бирелгән.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән

баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шулай ук әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;

– Бердәм портал аша;

– Республика порталы аша;

– ЕИС «Имущество» аша;

– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – Министрлык;
6. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
7. Россия Федерациясе Җир кодексы – РФ ҖК.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе проекты | Коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте (СНТ) яки коммерциячел булмаган яшелчәчелек ширкәте (ОНТ) әгъзасы, РФ ҖК $39^3$ статьясының 2 пунктының 3 подпункты нигезендә коммерциячел булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән бакча җир кишәрлеген яисә яшелчә җир кишәрлеген биргәндә | 1А |
| 2. | | җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат, РФ ҖК $39^9$ статьясының 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш | 2А |
| 3. | | «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда крестьян (фермер) хуҗалыгы яисә авыл хуҗалыгы оешмасы | 3А |
| 4. | | авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегенең арендаторы булган | 4А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | гражданин | |
| 5. | | авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегенең арендаторы булган юридик зат | 5А |
| 6. | җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе проекты | шәхси торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗына бакчачылык өчен җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында яисә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза биргән граждан | 6А |
| 7. | | гариза бирүченең вәкиле | 7А |

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | | Россия Федерациясе Президенты Указы яисә боерыгы нигезендә, РФ ЗК $39^6$ статьясының 2 пунктының 1 подпункты нигезендә юридик зат | 1Б |
| 2. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килүе шарты белән, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пунктының 2 подпункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе буенча социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен юридик зат | 2Б |
| 3. | | Татарстан Республикасы | 3Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | законнарында билгеләнгән критерийларга туры килүе шарты белән, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пунктының 3 подпункты нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе күрсәтмәсе буенча социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен юридик зат | |
| 4. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | җир кишәрлеген «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законга таянып банкрот дип танылган йорт салучыга, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 ел, 30 декабрь, № 214-ФЗ Федераль законы нигезендә акчалары күпфатирлы йортлар төзелешенә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар алдында йорт салучы йөкләмәсен башкаруны тәэмин итү өчен, «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законның $201^3$ статьясың 1 пункты | 4Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | нигезендә кредиторларның таләпләрен һәм бурычлының мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча арбитраж суд тарафыннан чаралар кабул ителгән очракта | |
| 5. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | җир кишәрлеген «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законга таянып банкрот дип танылган йорт салучыга - «“Территорияләрнең үсеше фонды” гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29 июль, 2017 ел, № 218-ФЗ Федераль законга таянып, гражданнар алдында күпфатирлы йорт төзелешен тәмамлау яки бурычларын кайтару йөкләмәсен кабул итеп алган “Территорияләрнең үсеше фонды” гаммәви-хокукый компаниясенә бирү өчен; | 5Б |
| 6. | | юридик зат, Россия Федерациясенең халыкара бурычларын үтәү өчен, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 4 подпункты нигезендә | 6Б |
| 7. | | юридик затларга электр, җылылык, газ һәм су тәэмин итү, су агызу, элемтә өчен | 7Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | билгеләнгән объектларны, нефть үткәргечләрне, федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдәге объектлары урнаштыру өчен биргәндә, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 4 подпункты нигезендә | |
| 8. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлеген, шул исәптән территорияне комплекслы үзләштерү өчен әлеге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе төзелгән затка бирелгәндә, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 8 подпункты, РФ ҖКның 46 статьясының 5 пункты, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 подпункты 5 подпункты белән башкасы каралмаган очракта | 8Б |
| 9. | | җир кишәрлеге коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлеге бирелгән СНТ яки ОНТ әгъзасы, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 7 подпункты нигезендә | 9Б |
| 10. | | СНТ яки ОНТ әгъзаларының гомуми җыелышы карары буенча гариза бирергә вәкаләтле зат, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 8 подпункты нигезендә | 10Б |
| 11. | | җир кишәрлеген өлешләп төзелештә катнашучыларга, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә | 11Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 ел, 30 декабрь, № 214-ФЗ Федераль законында каралган очракларда, РФ ҖК $39^{6}$ статьсының 2 пункты $8^{2}$ подпункты нигезендә | |
| 12. | | төзелеп бетмәгән объектлар милекчеләре, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 5 пунктында каралган очракларда, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 10 подпункты нигезендә | 12Б |
| 13. | | юридик затлар даими (вакыты чикләнмәгән) файдалана торган җир кишәрлеге әлеге җирдән файдаланучыларга бирелгәндә, РФ ҖК $39^{9}$ статьясының 2 пунктында күрсәтелгән юридик затлар һәм андый җир кишәрлегенең шәхси милектә була алмавы искәрмә булып тора, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 11 подпункты нигезендә | 13Б |
| 14. | | физик затлар даими (вакыты чикләнмәгән) файдалана торган җир кишәрлеге әлеге җирдән файдаланучыларга бирелгәндә, җир кишәрлеге РФ ҖК гамәлгә кергәнче гомерлек мираска алынып даими (чикләүләрсез) файдалануга бирелгән һәм андый җир кишәрлеге шәхси милектә булган физик затлар искәрмә булып тора, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 11 | 14Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | подпункты нигезендә | |
| 15. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | крестьян (фермер) хуҗалыгына яки авыл хуҗалыгы оешмасына бирелгәндә, “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында” 2002 елның 24 июлендәге № 101-ФЗ Федераль законда билгеләнгән очракларда, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 12 подпункты нигезендә | 15Б |
| 16. | | Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып, территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзелгән затка, яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып территориянең комплекслы үсеше мәсьәләләренең үтәлешен тәэмин итүче юридик затка РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 13 подпункты нигезендә | 16Б |
| 17. | | федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә беренче чиратта яки чираттан тыш җир кишәрлегенә ия булу хокукы булган гражданнар РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 14 подпункты нигезендә | 17Б |
| 18. | | җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән гражданинга торак пункты чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, | 18Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен РФ ҖК $39^{18}$ статьясының 5 пунктында каралган очракларда, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 15 подпункты нигезендә | |
| 19. | жир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | гражданин яки юридик затка арендага бирелеп, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына, РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 16 подпункты нигезендә | 19Б |
| 20. | | дини оешмаларга авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру өчен РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 17 подпункты нигезендә | 20Б |
| 21. | | Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән территориядә авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру, казак җәмгыятьләренең традицион яшәү һәм хуҗалык итү рәвешен саклау һәм үстерү өчен Россия Федерациясе казак җәмгыятьләре дәүләт реестрына кертелгән казак җәмгыятьләренә (алга таба - казак җәмгыятьләре) РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 17 подпункты нигезендә | 21Б |
| 22. | | дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен резервта булган яисә аның әйләнеше чикләнгән булса, РФ ҖК нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген | 22Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сатулашуларсыз, шул исәптән, түләүсез, алу хокукына ия булган затлар, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 18 подпункты нигезендә | |
| 23. | | җир кишәрлеген печән чабу, авыл хуҗалыгы малларын көтү, яшелчәчелек өчен яисә торак пункты чикләренең аръягында урнашкан җир кишәрлеге шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сораган гражданинга РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 19 подпункты нигезендә | 23Б |
| 24. | | җир кишәрлеге, файдалы казылмалар буенча эш алып бару өчен, файдалы казылмалар белән эш итүчеләр РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 20 подпункты нигезендә | 24Б |
| 25. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | махсус икътисадый зона резидентына РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 21 подпункты нигезендә | 25Б |
| 26. | | махсус икътисадый зона турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителгән идарәче компаниягә махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янындагы территориядә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш финанс чыганаклары хисабына күчемсез милек объектлары төзү буенча функцияләр башкару һәм | 26Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | әлеге һәм алдарак төзелгән күчемсез милек объектлары белән идарә итү өчен РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 21 подпункты нигезендә | |
| 27. | | Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы белән махсус икътисадый зона инфраструктурасын үстерү өлкәсендә үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелгән зат РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 22 подпункты нигезендә | 27Б |
| 28. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | концессион килешү төзелгән зат РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 23 подпункты нигезендә | 28Б |
| 29. | | коммерция өчен кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзегән зат РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты $23^1$ подпункты нигезендә | 29Б |
| 30. | | социаль кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик зат РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты $23^1$ подпункты нигезендә | 30Б |
| 31. | | махсус инвестицион контракт төзелгән юридик зат, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты $23^2$ подпункты нигезендә | 31Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 32. | жир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | сунарчылык хуҗалыгы килешүе төзелгән зат РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 24 подпункты нигезендә | 32Б |
| 33. | | сусаклагычлар һәм (яки) гидротехник корылмалар урнаштыру өчен җир кишәрлеге сораган зат РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 25 подпункты нигезендә | 33Б |
| 34. | | «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 26 подпункты нигезендә | 34Б |
| 35. | | «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 27 подпункты нигезендә | 35Б |
| 36. | | су биологик ресурсларын табыштыру (тоту) хокукына ия булган затка РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 29 подпункты нигезендә | 36Б |
| 37. | | товар аквакультурасы (товар балыкчылыгы) җитештерүче затка РФ ҖК 39$^{6}$ статьясының 2 пункты 29$^{1}$ подпункты нигезендә | 37Б |
| 38. | | атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклау пунктларын, саклагычларны һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру өчен юридик затка РФ ҖК | 38Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | $39^6$ статьясының 2 пункты 30 подпункты нигезендә | |
| 39. | | авыл хуҗалыгы производствосы алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегенең арендаторы булган гражданинга яки юридик затка РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 31 подпункты нигезендә | 39Б |
| 40. | | җир кишәрлеген арендалау өчен яңа шартнамә төзелергә хокукы булган җир кишәрлеге арендаторы РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 32 подпункты нигезендә | 40Б |
| 41. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | «Торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыруга һәм территориянең башка үсешенә ярдәм турында» 2008 ел, 24 июль, № 161-ФЗ Федераль законга нигезләнеп юридик зат яки физик зат РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 35 подпункты нигезендә | 41Б |
| 42. | | «Инновацион фәнни-технологик үзәкләр турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29.07.2017 № 216-ФЗ Федераль закон нигезендә оештырылган фонд РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 37 подпункты нигезендә | 42Б |
| 43. | | “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” | 43Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге № 435-ФЗ Федераль законы нигезендә “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” гавами-хокукый компаниясенең агымдагы елда һәм план периодында РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 40 подпункты нигезендә | |
| 44. | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | «Территорияләрнең үсеше фонды» гавами-хокукый компаниясе РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 41 подпункты нигезендә | 44Б |
| 45. | | “Территорияләрнең үсеше фонды” гавами-хокукый компаниясенә «Түләргә сәләтсезлек (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законда каралган нигезләр буенча РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пункты 42 подпункты нигезендә | 45Б |
| 46. | | “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга туры китереп газ белән тәэмин итү бердәм системасы объектлары милекчесе булган оешма, шул исәптән, җир кишәрлеге казылма байлыкларны | 46Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты | куллану өчен тәгаенләнгән булса да РФ ҖК $39^{6}$ статьясының 2 пункты 44 подпункты нигезендә | |
| 47. | | Гариза бирүченең вәкиле | 47Б |

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар | Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр (бюджет, казна, автоном) | 1В |
| 2. | | Казна предприятиеләре | 2В |
